УДК 821.512.145:070

***В.З. Гарифуллин***

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ЖУРНАЛИСТЛЫК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье анализируется журналистская деятельность и публицистическое творчество выдающегося организатора татарской периодической печати, писателя и общественного деятеля Фатиха Амирхана. В начале XX века Ф. Амирхан становится ключевой фигурой в становлении системы татарской прогрессивной журналистики. В центре внимания его публицистического творчества – борьба против самодержавия, реформы в области образования, пути развития татарской литературы, разработка норм литературного языка.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, история татарской журналистики, периодическая печать, публицистика, статья, сатира.

XX гасыр башында дөньяга аваз салган татар вакытлы матбугаты бик тиз арада зур үсешкә ирешә. Чөнки аның башында халык мәнфәгатьләре белән яшәгән бөек шәхесләребез торган. Шуларның берсе – матур әдәбиятта гына түгел, журналистика өлкәсендә дә тирән мәгънәле әсәрләр калдырган, татар журналистикасының тууына, үсүенә һәм алга китүенә зур йогынты ясаган Фатих Әмирхан. Аның журналист эшчәнлеге күләме белән дә, хронологик кысалары белән дә саллы, ул вакытлы матбугат үсешендәге берничә чорны үз эченә ала.

Журналист буларак Ф. Әмирхан күп төрле газета-журналлар белән хезмәттәшлек иткән. Аларның беришендә – «Тәрбиятел-әтфал» журналында, кулъязма һәм басма «Әльислах», «Кояш» газеталарында җаваплы сәркатип сыйфатында эшләсә дә, ул – аларның фактик редакторы, икенчеләрендә – «Аң», «Яшен», «Ялт-йолт» кебек журналларда, «Эш», «Кызыл армия», «Татарстан хәбәрләре» кебек газеталарда төрле жанрларда һәм төрле темаларга язылган әсәрләре белән катнашкан. «Ф. Әмирхан публицистика арсеналындагы күп төрле формалардан файдаланган, иң катлаулы саналган очерк, фельетон жанрларында эшләгән, бөтенләй сирәк кулланыла торган рецензия-памфлет, интервью-фельетон, физиологик очерк кебекләрен дә язган. Аның публицистикасының палитрасы киң: бу өлкәдә ул – зур колачлы фикер иясе, үткен сатирик, нечкә хисле лирик» [Нуруллина, б. 232].

Революцион вакыйгалар нәтиҗәсендә туган татар вакытлы матбугаты Ф. Әмирханның журналистлык эшчәнлеге үсүгә киң мәйдан ача. 1906 елның көзендә ерак кардәше Заһид Шамил чакыруы буенча Фатих Әмирхан Мәскәүгә килә һәм «Тәрбиятел-әтфал» журналында җаваплы сәркатип булып эшли башлый, шушы басманың мәсләген билгели. Басманың баш мәкаләләре,

фәнни-популяр мәкаләләр (татар журналистикасында фәнни-популяр публицистиканың башлангычы) аның тарафыннан языла, тәрҗемә рәвешендәге әдәби әсәрләре дөнья күрә.

Казанга кайткач, Ф. Әмирхан педагог һәм журналист Вафа Бәхтияров белән «Әльислах» газетасын чыгара башлауга ирешә. 1907 елның 3 октябрендә аның беренче рәсми саны дөнья күргән. Рәсми редакторы В. Бәхтияров булса да, «Әльислах»ны фактик оештыручы һәм җитәкләүче Ф. Әмирхан була. «Газетаның татарда демократик фикерне җәелдерүдә әһәмияте искиткеч зур. Ф. Әмирханның әдәбиятка, сәнгатькә кагылышлы бик күп тәнкыйть мәкаләләре, Казан хәлләре, иҗтимагый мәсьәләләргә багышланган очерклар, информацияләрнең зур күпчелеге «Әльислах»та басыла» [Нуруллин, б. 39]. Газетаның беренче санында ук басылып чыккан өч язмасы белән ул «Әльислах»ның төп кыйбласын, юнәлешен билгели. Баш мәкалә жанрындагы «Казан, 3 октябрь», шулай ук «Мөтәгәссыйб Казан татарларына ачык хат» һәм «Думалар» дигән язмалар – Фатих Әмирхан иҗатының югары дәрәҗәсен күрсәтеп торучы гаять җитди һәм үзенчәлекле әсәрләр. «Думалар» мәкаләсендә III Думага вәкилләр сайлау турында сүз бара. 3 июнь законы керткән чикләүләр, аларның Думада зур җирбиләүчеләр һәм фабрика-завод хуҗалары мәсләкләрен яклауны тәэмин итүе, ләкин барыбер сайланучылар арасында сулларның һәм урталарның күп булуы әйтелә һәм хөкүмәтнең, Думада уңнар өстенлек итәр, дигән «хисабы» «бөтенләй үк тугры чыкмас» дип нәтиҗә ясала [Әмирхан, б. 51]. Гомумән, Думаның эшчәнлеге, аның кемнәр кулында булуы, кемнәр җырын җырлавы Ф. Әмирханны даими кызыксындырган. Менә аның «Әльислах»та шул хакта басылган мәкаләләре: «3 нче июнь кануны вә партияләр», «3 нче Дума», «Дума ачылды», «Думада центр», «Зур педагоглар» зур эш эшләп кайттылар», «Мәктәп ляихәләре өчен аяклар!» һ.б. Боларда журналист ил тормышында хәлиткеч урын тоткан мөһим проблемалар турында сүз алып бара: кайсы сәяси партия нинди максатны алга куя һәм көчәя барган реакция аларга нинди йогынты ясый, яңа сайланган Думада хәлиткеч көч кемнәр кулында, Россиянең иҗтимагый-сәяси тормышы алга таба кайсы юлдан барачак, мәгариф алга тәрәккыят итәме? Осталык нисбәтеннән килеп караганда бу мәкаләләр – татар сәяси публицистикасының югары үрнәкләре.

«Әльислах» – хөр рухлы газета. Аның төп бүлекләре дә, төп тематикасы да күбесенчә җәмгыятьне алга таба үстерүгә юнәлтелгән. Ф. Әмирхан публицистикасында татар халкының мәгърифәтчелеген үстерү, мәктәп-мәдрәсәләрне дәүләт карамагына күчерү, уку-укыту эшләрен рус, Европа мәктәпләре үрнәгендә үзгәртү, көндәлек тормышка, хезмәткә кирәкле белем бирә торган дөньяви фәннәр кертү зарурлыгы кебек мәсьәләләрне күрәбез. Ф. Әмирхан халыкның рухи үсешен җайга салу, мәгариф һәм

мәдәният тормышын алга җибәрү өчен иң элек аның икътисадый хәлен үзгәртергә кирәк икәнлеген еш ассызыклый. «Әльислах»ның 1908 ел, 9 февраль санындагы баш мәкаләсендә: «...бер милләт арасында тәгъмиме мәгариф итәр өчен (гомумбелем алуны кертү өчен) иң әүвәлге шарт та – аларның әхвале икътисадиясен яхшы хәлгә китерүдер. Күз алдымызда: фәкыйрь милләт мәгарифтә гомумән тәрәкъкый итә алмаган шикелле, һәр милләтнең дә фәкыйрь әфрады, бөтен көннәрен фәкать үзләрен вә гаиләләрен ачтан үтермәс өчен сарыф итәргә мәҗбүр булып, мәгариф тәхсиленә бушый алмыйдыр», – дигән юллар бар [Әмирхан, б. 92]. «Көненә унбер сәгать кибеттә басып торган приказчиклар, көненә унбер-унике сәгать эшләп хәлдән тайган фабрик эшчеләре, ачлыктан йөдәгән крестьяннар вә балалары шул хәлләрендә калдырылган вакытта, алар өчен бер авылга, бер мәхәлләгә берәр түгел, унар мәктәп ачсаң да, әллә нинди мәгариф тарата торган җәмгыятьләр вөҗүдкә китерсәң дә, алардан файдалана алачак вә зыялана алачак түгелдер» [Шунда ук, б. 92–93]. 1908 елның 9 мартында басылган «Казан, 9 март» исемле баш мәкаләдә Ф. Әмирхан бу мәсьәләгә яңадан кайта: «Горфи бер крестьянга, бер рабочийга баласын ике-өч йөз сум расход тотып фән мәктәпләрендә укыту мөмкин түгеллеген кем инкяр итә аладыр? Мәкятибе галиягә фәкать кереп укыр өчен генә йөз сум түләргә кирәк булгач, анда укучылар күбрәге байлар булырга кирәклеге бик табигыйдер. Менә нәрсә өчен без, гавам халык мәгарифе аның әхвале икътисадиясе белән баглы, димез» [Әмирхан, б. 103].

Нинди генә темага язса да, Ф. Әмирхан саллы һәм ышандырырлык дәлилләр системасын оста эшкә җигә. «Әльислах»тагы «Тел мәсьәләсенә бер караш» (1908, 14 гыйнвар) дигән публицистик мәкаләсе авторның дәлилләү осталыгы уңаеннан аеруча игътибарга лаек [Әмирхан, б. 82–88].

Автор текстның башлам өлешендә телләр өлкәсендәге мөһим проблемаларны санап үтә, анналары җитди мисаллар белән фикерләрен дәлилләп бирә. Мәсәлән, тел мәсьәләсенең сәясәт белән турыдан-туры бәйләнеше турындагы тезис Польша, Австрия һәм Венгрия мисалында исбат ителә:

Тезис: *Тел мәсьәләсе күп заманнардан бирле сәясәткә дә иштирәк итеп килә вә актык елларга кадәр мөстәбид хөкүмәтләрнең башка милләтләргә каршы тоткан коралларыннан берсе булып киләдер.*

Дәлил: *Актык елларда поляларның шулкадәр мәшәкать белән тәкмил ителгән вә шулкадәр әдәбиятка мәлик булган телләренә каршы һөҗүмнәр, Австрия вә Маҗарстан парламентларындагы таяклар белән сугышлар һәммәсе шул җөмләдәндер.*

Тел һәм матур әдәбиятның бер-берсенә йогынты ясавы турындагы тезис та конкрет фактлар нигезендә дәлилләнә:

Тезис: *Телнең әсасән җуялуы, һичбер вакытта дияргә мөмкин, читтән ителгән һөҗүмнәрдән генә килмичә, бәлки телнең*

*әдәбиятының юклыгы вә эшләнмәгәнлегеннән киләдер.*

Дәлил: *Әдәбияты куәтле тел әллә нинди куәтле һөҗүмнәргә каршы да бирелми икәнлегене поляк теленнән вә фәнни истиляхларга бай телләр әллә нинди сәяси бәхетсезлекләргә дә чыдый икәнене хәзергә кадәр фәнни нәрсәләрдә истигъмаль ителә торган латин вә төрек телләреннән күреп белә аламыз.*

Аннары автор гарәп теленең башка, көчсезрәк телләргә йогынты ясавы турындагы фикерне үткәрә, дәлилләү өчен башка милләтләрнең күренекле вәкилләре гарәп культурасына хезмәт итүе турындагы фактларны китерә:

*Мисал уларак, тугрыдан-тугры гарәп теленә хезмәт иткән Габделкаһир, Фәйрүз абади, Зимәхшәри кебиләрне рәттән санап китәргә мөмкин.*

Ә инде татар теленең чит тел сүзләре, бигрәк тә гарәпнекеләр белән чуарлануы хакындагы фикерен Ф. Әмирхан «Әльислах» редакциясенә шәкертләрдән килгән хатлардан өзекләр белән дәлилли:

*...башындагы заказ язылган «зате сәгадәтелмәаб, хәзрәте галиҗәнаб» дигән сүзләрдән башлап, «мәдрәсәи бракдым, утамә сукылдыкымда Хуҗа әфәндеми күрдем. Ядеңези пус идеюрем» дип тәмам булганчы, минем күңелләрем болганып, тәмам саруларым кайнап бетәдер.*

Күргәнебезчә, алдагы өзекләрдән аермалы буларак, бу дәлилдә конкрет фактлар гына түгел, авторның *күңел болгану, сару кайнау* кебек фразеологизмнар белән белдерелгән эмоциональ рухтагы шәхси бәясе дә бар.

Татар теленең көчсезлеге һәм әдәби эшләнеп җитмәве турындагы тезисны тиешенчә дәлилләгәннән соң гына автор укучыны төп тезис белән таныштыра: татар зыялыларының бурычы – туган телне киң халык катлаулары аңларлык дәрәҗәдә камилләштерү. Аннары төп тезис ярдәмче тезислар ярдәмендә конкретлаштырыла, автор куелган максатка ирешү өчен мөһим булган җиде максатны аерып күрсәтә. Алар һәммәсе дә нигезле итеп дәлилләнә. Мәсәлән, ана телен камилләштерүдә язучыларга аеруча мөһим бурыч йөкләнүе турындагы тезисны Ф. Әмирхан рус теле мисалында дәлилли:

*Рус әдәбияты белән белеш кешеләргә мәгълүм: рус теле хәзерге хөснене фәкать Пушкин кеби берничә мөхәррирләрнең иҗтиһады соңында гына хаиз була алгандыр.*

Мәкалә төп тезиста билгеләнгән максатка ирешү юнәлешендәге конкрет тәкъдим белән тәмамлана:

*Занымча, хәзер тел хезмәтенә әсас куяр өчен, интисабле затлар җыелу шарты белән киң бер съезд игълан итәргә вә игълан иткәндә дә хәзерләнерлек кешеләр хәзерләнеп өлгерер дәрәҗәдә алдан игълан итәргә кирәктер.*

Мисал итеп китерелгән бу текстның төзелеше ныклап уйланылган. Башта автор укучыга үзе күтәргән проблеманың мөһимлеген раслый торган дәлилләр китерә, аннары әлеге проблеманы чишүнең юлларын күрсәтә, текст азагында проблеманы хәл итүгә юнәлдерелгән конкрет һәм реаль тәкъдимнәр кертә. Тезиста ман-

тыйкый дәлилләү өстенлек итә: барлык тезислар җитди фактлар белән беркетелгән. Шул ук вакытта дәлилләрнең кайберләре, тел чараларын уңышлы куллану нәтиҗәсендә, психологик тәэсир көченә дә ия. Мәкаләдә халык телен өйрәнү, әдәби һәм фәнни әсәрләрне гарәп, фарсы алынмаларыннан, грамматик элементларыннан арындыруның, әдәбият тарихын булдыруның һәм аның бүгенге үсешен тәэмин итүнең бөтен бер программасы бирелгән.

«Әльислах»ның үзенең теле дә ул вакытта чыга торган газеталарның теленнән бик нык аерыла. Монда госманчылык-төрекчелектән баш тартып, татар телен мөстәкыйль тел итеп тану чагыла. Ф. Әмирхан язмаларының теле бер яктан гади, икенче яктан бизәкләү чараларына, шулай ук шәхсилекне ассызыклаучы чараларга бай булуы белән аерылып тора. Ул, җәмгыятьне дулкынландырган мөһим социаль күренешләрне чагылдырып, аларга карата үзенең шәхси мөнәсәбәтен белдерә, шул ук вакытта зур гомумиләштерүләр дә ясый. Текстларын төзегәндә кабатланмас алымнарга мөрәҗәгать итә. Әйтик, «Әльислах»та чыккан «Авырулар галәмендә» исемле язмасын (1908, 20, 27 июнь, 14 август) ул көчле контрастлар кулланып иҗат иткән [Әмирхан, б. 123–132]. Автор табигатьтәге тигезсезлек һәм шәфкатьсезлек белән кешелек дөньясындагы тигезсезлек арасында параллель уздыра:

*Әй сез, агачлар, ник берегез озын да, берегез кыска булып үстегез? Кем сезнең белән шаярды? Кемгә сезнең берегез озын булганда, икенчегезнең кыска калуы кирәк булды?*

Шулай да текст авторы социаль тигезсезлекнең юкка чыгачагына ышаныч белән карый. Язманың соңгы юллары оптимистик рухта:

*И таң, ат инде тиз генә! Мин сине көтәм һәм тиздән булуыңа ышанам.*

Шулай итеп, кешеләрне яшәү ләззәтеннән мәхрүм итә торган чирләр иҗтимагый тормыштагы тигезсезлек, золым һәм кара көчләр бер рәткә куела. Авырудан, табигатьтән зарлануның социаль тигезсезлекне күреп эч пошудан, реакциянең көчәя баруыннан килеп чыгуы аңлашыла. Әмма бу хисне тормышның яңарачагына, прогрессив көчләрнең котылгысыз рәвештә җиңәчәгенә ышаныч җиңә. Бу язманың жанрын сәяси эссе буларак билгеләргә мөмкин.

Үз иҗатында Фатих Әмирхан хат күзәтү жанрына да зур игътибар биргән. Аның «Гәзитәләр галәменнән» дигән язмасы (Әльислах, 1908, 14 гыйнвар) шушы жанр өчен хас үзенчәлекле төзелешкә ия [Әмирхан, б. 91–92]. Язмадагы һәр яңа тезис риторик сорау белән беркетеп куела:

*«Вакыт» гәзитәсе бик тырышып-тырышып социализм белән сугыша, ахыргы номерда «Җыелыңыз, бөтен дөнья эшчеләре!» дип башлап бер мәкалә язып, социалистлардан бик хур итеп көлде.*

*Фәкать шуны гына беләсе иде: мондый һөҗүмнәрдән социализм фикеренең ничә шөребе какшады икән?*

*Әстерханда нәшер ителә торган «Идел» гәзитәсе бик*

*тырышып «Шураи Ислам» белән сугыша.*

*Шуны беләсе иде: кайчан аңар җеназа укырга тели икән?*

*«Әхбар» гәзитәсендә Г. Ибраһимовның «Менә шундый вакытларда русның табигате яхшы күренә инде» дип, бөтен рус милләтенә бер-ике кешенең эшләгән эшләрен иснад иткән мәкаләләре языла башлады.*

*Беләсе иде: рус милләте мондый һөҗүмнәргә ничек итеп кайгыра икән?*

*...«Әльислах» гәзитәсе дүртенче ай мәдрәсәләр мәсьәләсен чәйни.*

*Беләсе иде: кайчан өзәрем дип уйлый икән?*

Автор үзе тәкърар иткән тезисларның тискәре характерын бер үк калыптагы риторик сорау җөмләләрне (Шуны беләсе иде..., беләсе иде...) кабатлаулы куллану аша гына түгел, алар составындагы лексик-фразеологик характердагы көлкеле сурәтләү чаралары белән дә (һөҗүм, ничә шөребе какшады, җеназа укырга, кайчан өзәрем дип уйлый) белдерә. Текстның әнә шундый үзенчәлекле төзелеше нәтиҗәсендә берничә татар вакытлы басмасының юнәлеше сатирик рәвештә кискен тәнкыйть утына тотыла.

Ф. Әмирхан публицистикасында аерым урынны сатира алып тора. Әйтик, «Кечкенә фельетон (Гласный булган идем дә, 300 шар җитми калды)» исемле фельетоны – сатирик публицистиканың матур бер үрнәге булып тора [Әмирхан, б. 151]. Публицист биредә сатираның көчен искелеккә, торгынлыкка каршы юнәлдерә. Татар журналистикасында беренчеләрдән булып Фатих Әмирхан вакытлы матбугат битләрендә диалогик төзелешле текстлар бастыра. Мондый әсәрләргә (мәсәлән, интервьюга) карата куела торган мөһим таләпләрнең берсе – әңгәмәдәшнең сөйләм үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклау. Моның өчен автордан телнең мөмкинлекләрен яхшы белү сорала. Кызганыч ки, бүгенге журналистикадагы диалогик язмаларның күпчелегендә әйтелгән таләп төгәл үтәлми. Ф. Әмирхан әсәрләрендә исә сөйләшүдә катнашучыларның индивидуаль сөйләм үзенчәлекләре гаять оста бирелә. Бу уңайдан аның «Әльислах» газетасында чыккан һәм диалогик текст формасында язылган «Зурлар белән мәдрәсәләр берләштерү хакында мөзәкәрә» дигән фельетоны игътибарга лаек [Әмирхан, б. 110–116].

Бу әсәрен автор язманың темасы игълан итүдән һәм әңгәмәдәшләр белән таныштырудан башлап җибәрә:

*«Әльислах» мөхбирлеге сыйфатым белән Казан мәшаһиренең мәдрәсәләр берләштерү хакындагы фикерләрен сораштырып йөрдем. Әүвәл бу мәсьәләдә бик мөһим урын ишгаль иткән кешеләр дип муллаларга барырга карар биреп, алар арасында да картрак вә зуррак дәрәҗәлесе дип ахундка бардым.*

Аннары автор Йосыф ахун белән булган сөйләшүен тәкъдим итә:

*Йосыф хәзрәттә.*

*Мин:*

*– Тәхсир, хәзер мәдрәсәләр берләштерү мәсьәләсен кузгат-*

*тылар. Шул тугрыда сезнең дә фикереңезне белергә телим.*

*Ахун:*

*– Әнәтерәк, инде һәммәсен дә бер ясыймыз диләрмени? Әнәтерәк, мулла Галимҗанмы инде? Шулай димени инде?*

*Мин:*

*– Тәхсир, шулай диләр.*

*Ахун:*

*– Әнәтерәк, байлар ни диләр соң?*

*– Белмим.*

*– Әнәтерәк, без байлардан узмамыз инде. Шулай инде. Мулла Галимҗан минем мәдрәсәне бетермәкче димени инде?*

Ф. Әмирхан әңгәмәдәшенең сөйләм үзенчәлекләре аша аның характер чалымнарын да тапшыра алган. Сораугa сорау белән җавап бирү – икеләнү, ныклы фикер булмау билгесе. Автор ахунның сөйләм үзенчәлекләре аша (әнәтерәк, инде кебек паразит сүзләр куллану) аның үз фикерләрен беркадәр ашык-пошык, уйлап җиткермичәрәк әйткәнен дә белдерә алган.

Ә менә Галимҗан хәзрәтнең уйланган, төпле һәм төгәл җаваплары аның тыныч холыклы, вәкарьле (автор моңа үзе дә басым ясый) кеше икәнлеген ассызыклый:

*Галимҗан хәзрәттә.*

*– Тәхсир, тәүхиде мәдарис хакында фикереңез?*

*(Вәкарь белән генә):*

*– Мәдрәсәләрне берләштерү, инша аллаһ, файдадыйн хали булмаз. Аллаһ вә рәсүлә ризалыгы сарый ашыгучылар бу эштә гыйнад вә мөкябәрә итмәскә лязем-дер. Берләштерү матди җәһәт сартин да файдадин хали булачак дәгел.*

*– Рәхмәт, әссәләмәгаләйкем.*

Кыска гына диалогик өзектән әңгәмәдәшнең гаять динле кеше булуы (*инша аллаһ, аллаһ вә рәсүлә ризалыгы сарый ашыгучылар* кебек гыйбарәләр), өстәвенә дини гыйлемнәргә ия кеше булуы ачыклана.

Тагын берничә дин әһеле янында булганнан соң, Ф. Әмирхан газета мөхәррирләренә сорау бирә. Алар арасыннан Һади Максудиның сөйләме гади һәм аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Ә Борһан Шәрәфнең сөйләм үзенчәлекләреннән аның кызу канлы, тиз кабынучан һәм хисле кеше булуын чамаларга мөмкин. Аның бу үзенчәлекләрен сөйләмендәге сорау, өндәү һәм тойгылы җөмләләр, риторик сораулар, ымлыклар (*ha-ha*), кабатлаулар (*фикерме – фикер; шул Казан муллаларыннан – шул бары алар өстеннән кеше көлсен өчен генә яратылган кешеләрдән; кайда эш эшли алганнары бар – кайда зарар китерми калганнары бар; берләштерү дә булмый – башка да булмый*), шулай ук ремаркалар аша әңгәмәдәшнең ишарәләрен тасвирлап бирү кебек чаралар тапшыра.

Әсәр автор сөйләменә караган түбәндәге очлам белән төгәлләнә:

*Мәзкүрә әфкяре кыл кадәр улсын ихтирафтан башка тәблигъ иттек.*

Чынлап та, сөйләм ияләренең фикерләре дә, тел чаралары да бер-берсеннән нык аерылып торуы бу фикерне тагын бер кат раслый.

Ф. Әмирхан күп кенә сатирик әсәрләрендә кадими

мәдрәсәләрдә укыту рәвеше, тәрбия чараларының искергәнлеген, мәгънәсезлеген кискен тәнкыйтьли. «Мәктәпләрдә хөррият рухы», «Зыялы» шәкерт» фельетоннары, «Егерменче гасыр әфьюнчысы» дигән памфлет-рецензия әнә шул максаттан язылган.

«Әльислах»та Ф. Әмирхан, фикердәше Г. Тукай белән берлектә, татар әдәби тәнкыйтенә нигез сала, шагыйрь белән дуслыгы тагын да ныгый. Газетада ул татар әдәбияты торышы, аның үсеше проблемаларын тикшерүгә киң урын бирә. «Әдәбият кичәсе», «25 ндә татарча театр уены», «Әдәбиятка гаид», «Мәктәпләребездә әдәбият дәресләре», «Татарча спектакльләр» исемле мәкаләләрендә татар халкында «мәгыйшәте гомумиянең» башлануына зур шатлану белдерелә. Әдип бу публицистик әсәрләрендә татар яшьләре күңелендә «әдәбият, театр», «музыка вә хәяте гомумия хиссиятләренең» нык урын алачакларына ышана һәм татар халкында «әхлакы хәсәнә тәгаммем» итә башлавына чын күңелдән сөенә. «Әльислах» битләрендә «Яңа китаплар» яки «Китаплар хакында мөхакәмә» дигән аерым бер бүлек тә яшәп килә. Анда яңа әсәрләргә багышланган рецензияләр урнаштырып барыла. Ф. Әмирхан тәнкыйди публицистика жанрында гаять актив эшли. Фикердәшләренә таянып, ул тулаем әдәбият-сәнгать проблемаларына гына багышланган яңа журнал чыгару идеясе белән яна башлый. Нәтиҗәдә, 1912 елның декабрь уртасында әдәбият, сәнгать юнәлешендәге «Аң» журналы чыга башлый. Г. Тукай беренче сан өчен махсус «Аң» исемле шигырь иҗат итсә, Ф. Әмирхан «Шәрекъ йоклый» дигән мәкаләсен яза. Исеменнән үк аңлашылганча, Ф. Әмирхан халыкны озакка сузылган йокыдан уянырга чакыра. «Аң» моннан соң да аның әсәрләренә киң урын бирә. Фатих Әмирхан исә бу чорда үзенең бөтен тырышлыгын яңа матбугат органы – «Кояш» газетасына күчерә. Биредә ул карагруһчылыкны, милләтчелекне, империалистик дәүләтләрнең реакцион халыкара сәясәтен тәнкыйть иткән байтак материал урнаштыра.

1913–1917 елларда татар әдәбияты, публицистикасы һәм тәнкыйтендә Ф. Әмирхан кадәр актив эшләүче булмый, дип билгеләп үтә М. Мәһдиев [Мәһдиев, б. 78]. Чөнки бу вакытта Г. Тукай вафат, Г. Камал һәм Г. Коләхмәтов авырыйлар, Ш. Камал «Акчарлаклар»дан соң тынып калган, Г. Ибраһимов зур романга керешкән. Ф. Әмирхан бөтен татар әдәбияты, мәдәнияте мәсьәләләре өстендә берүзе эшли, көн-төн яза.

Совет власте елларында да Ф. Әмирхан иҗтимагый тормыштан читтә яшәми. «Кызыл Армия», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре» газеталарында, «Шәрекъ кызы», «Кызыл шәрекъ», «Безнең юл» журналларында яңа тормыш идеалларын пропагандалый.

Ф. Әмирхан публицистикасы төп сыйфатларының берсе – максат аныклыгы. Ул нәрсә өчен язганын, нәрсәгә ирешергә теләгәнен аңлап эш иткән. Шул максатына ирешү өчен журналистик чараларны дөрес сайлый

һәм барлык жанрларда да бертигез әйбәт яза белгән. Ф. Әмирханның иҗтимагый-сәяси темага язылган очерк һәм мәкаләләре җитди гомумиләштерүләргә ия. Җәмгыятьтә яшәп килгән тискәре күренешләрне тәнкыйтьләү өчен ул фельетоннар язган. Киң колачлы проблемалар куярга мөмкинлек бирә торган жанрлардан тыш, Ф. Әмирхан рецензия, интервью, репортажларны яратып кулланган. Аның күренекле язучылар иҗатына, яңа дөнья күргән китапларга багышланган рецензияләре тирән эчтәлеккә ия. Ф. Әмирхан хисап, хәбәр, репликаны да эшкә җиккән. Аларны матбугатның иң хәрәкәтчән, җитез, үтемле формалары дип санаган.

Ф. Әмирханның матбугат һәм журналистикага карашлары кызыклы. Вакытлы матбугат нинди булырга, нәрсәләр турында язарга, халык белән нинди элемтәдә булырга тиешлеге 1913 елны дөнья күргән «Төркстан шивәсендә матбугаты мувәкъкатә» исемле мәкаләсендә ачык чагыла [Әмирхан, б. 230–234]. Бу мәкалә бүген дә аерым өйрәнүгә лаеклы. Ул татар матбугатының беренче көннәреннән үк мәгърифәтчелек һәм халык азатлыгы рухында эшләвен күрсәтә. Мисал буларак, Ф. Әмирхан Төркстанда чыгарылып килгән берничә газетаны тасвирлап китә – мөхәррирләре, газеталарның юнәлешләре турында сүз йөртә, Сәмәрканд халкының газета алдырмау сәбәпләрен ачыклый. «Сәмәрканд» газетасының мөхәррире – «үзе төркстанлы, Төркстанның шивәсен дә, тормышын да яхшы белә торган голәма хезмәтендәге зат булганга күрә, аның гәзитәсенең Төркстан өчен кирәкле бер гәзитә булып чыгуы бик өмидле иде» [Шунда ук, б. 232]. Ләкин бу газета, укучылары булмау сәбәпле, чыгудан туктый яза. Ни өчен? Газета көндәлек түгел. Димәк, ул, беренчедән, хәбәрләрне вакытында ирештереп тора алмый. Икенчедән, анда барлык хәбәрләр өчен урын җитмәячәк. Димәк, газета аларны «бик чүпләп кенә дәреҗ итәргә, бик күп нәрсәләрне бөтенләй дәреҗ итми узарга мәҗбүрдер» [Шунда ук]. Газетаның ике номеры арасында шактый вакыт үтә. Укучылар вакыйгаларның тәртибен һәм «мантыйкый төзелешен югалтып өлгерә», алар вакыйгаларның эзлеклелеген югалталар. Шуңа күрә «халык матбугаты мувәкъкатәдән ләззәт алырга өйрәнми, ягъни үзенең истикъбале өчен мөштәриләр хәзерли алмый» [Шунда ук]. Икенче яктан, газета ни өчен көн саен чыкмый? Чөнки мөхәррирләр газетаның көн саен чыгып торган ихтималда сатып алынып бетүенә ышанмыйлар шикелле.

Ф. Әмирхан газетаның көн саен чыгып торуы мәҗбүри икәнен әнә шулай аңлата. Бу – вакытлы матбугат өчен беренче шарт. Көн саен булмаса, газета атнага һич югы дүрт тапкыр чыгарга тиеш. Дөрес, кемнәрдер: «Моның өчен зур капитал кирәк», – диярләр. Әмма Ф. Әмирхан аларга: «Бу капиталны табарга кирәк», – ди. Бәлкем, бер-ике ел мөхәррирләр файда урынына зарар күрерләр, әмма шул арада халык газетага «комарланып өлгерер»,

дип фикер йөртә Ф. Әмирхан. Һәрхәлдә, газетаны чыгаручылар әнә шуңа ашкынырга тиеш. Ә аннан соң газета инде «үз расходын үзе күтәрә башлый вә, яңадан берәр ел үткәч, һич шөбһәсез, наширләренә файда китерә башлый» [Шунда ук, б. 233]. Бу уңайдан Ф. Әмирханның мөхәррирлек хезмәтенә бәйле бер истәлек кызыклы. К Мостакаев язучыдан «Әльислах»ның торышы турында сорый:

«Үз нәүбәтемдә мин дә Фатихтан “Әльислах” турында сораштырдым. Ул теләр-теләмәс кенә итеп:

– Хәзергә мәгънәви яклары канәгатьләндерми әле, ә материаль ягына килсәк, анысы инде безнең, шул җөмләдән сезнең дә, халыкны ни дәрәҗәдә мавыктырырлык тырышып эшләвебезгә бәйләнгән» [Мостакаев, б. 79].

Димәк, Ф. Әмирхан газетада басылган материалларның эчтәлегенә бик зур әһәмият биргән. Ә матди ягын газетаның эчтәлегенә бәйле дип санаган. Икенче шарт – газеталарда илдә барган вакыйгаларның барлык нечкәлекләрен җентекләп сурәтләп бару. Ягъни газета алдыручылар «комарлансын» өчен шартлар тудыру. Бу очракта без Ф. Әмирханның көн тәртибендә торган материаллар турында сүз йөрткәнен аңлыйбыз. Укучы бүген ни турында уйлый, нәрсәләр турында укырга тели – журналист әнә шуларны белергә һәм язарга тиеш. Көндәлек вакыйгаларны сурәтләп барган газета һәр көн укучы тарафыннан көтеп алына.

Өченче шарт үзеннән-үзе алдагылардан килеп чыга – вакытлы матбугатта сурәтләнгән вакыйгаларның үзара эзлеклелеге, логик бәйләнеше саклану. «Җитди вә хәзалыкның рухын вә мәнафигын аңлап яза торган бер гәзитә лязем», – дип яза Ф. Әмирхан [Әмирхан, б. 232]. Бүген бер нәрсә турында башлап, иртәгесен икенче нәрсәгә сикереп, яза башлаганны ташлап, ярты юлда калдырып киткән матбугат җитди укучыга кирәкми. Шуңа күрә ул көндәлек булырга да мөмкин түгел. Аны көн саен алмаячаклар.

Әлбәттә, газета алдырып китсен өчен, аның башында тәҗрибәле мөхәррир тору мәҗбүри. Ф. Әмирхан илдә хәтта хөррият булмаганда да, газета, шундый мөхәррире булганда, чиновникларга артык бәйле булмыйча, басылудан тукталмаячак, ди һәм мисалга Исмәгыйль Гаспринскийны һәм аның газетасын китерә.

Газета сәяси яктан уртача булырга, милли мәсьәләләрне ишарәләр белән генә әйтергә, ачык дәгъвалар урынына нокталар гына куеп китәргә мөмкин, әмма ул яшәсен, халыкны укырга, вакытлы матбугатны дөньяны күзәтергә өйрәтсен, халыкка мәдәният алып барсын – аның бурычлары әнә шул! Бүгенге журналистикабыз өчен дә гаять мөһим фикерләр бу.

Фатих Әмирханның журналистика өлкәсендәге бөтен булган иҗаты да милләтне тәрәккъыят иттерүгә, халыкны рухи азатлыкка алып чыгуга, дөньяның алдынгы милләтләреннән берсенә әверелдерүгә хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр. 4 томда. III том. Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

*Нуруллин И.З.* Прометей из Новотатарской слободы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. 270 с.

*Нуруллина Р.М.* Тарих яза каләмем... Казан: Казан ун-ты нәшр., 2009. 336 б.

*Магдеев М.С.* Фатих Амирхан: Краткий очерк о жизни и творчестве писателя. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 83 с.

*Мостакаев К.* Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан белән күрешү // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 76–82.

***Гарифуллин Васил Заһит улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*татар журналистикасы кафедрасы мөдире*